# SOCIO-POLITICAL MOVEMENT OF TATARS IN CENTRAL ASIA IN THE EARLY 20TH CENTURY

**Dzhaudat Salimovich Minnullin,**
Kazan Federal University,
18 Kremlyovskaya Str., Kazan, 420008, Russian Federation.
zminnullin@mail.ru.

The article highlights the socio-political movement of Tatars in Central Asia in the early 20th century. The research has revealed more than 36 different socio-political organizations, functioning in the cities of Tashkent, Andizhan, Samarkand, Fergana, etc. in Central Asia (the territory of the modern Republic of Uzbekistan). After the February Revolution of 1917, the Tatar socio-political movement rose to a new level: Tatar print media began developing in the Region, and Kurultay (National Congress) was convened on the initiative of Tatar central authorities. However, the independent Tatar socio-political movement was abolished with the establishment of the Soviet regime.

**Key words**: Central Asia, youth, women, cultural and educational charitable organizations, diaspora, congress.

The history of Tatar diaspora is one of the new directions of Tatarstan history that emerged in the 90s of the last century. Although there are some special research and monographs dedicated to this issue, there is still a lot of work to be done in this field for many historical problems are out of scholars' sight. For instance, the recent works on the socio-political movement in Central Asia in the early 20th century do not mention the Tatar organizations at all [Abdullaev], [Atadzhanov], [Khafizov].

The Tatar diaspora was considered to be the largest one in Central Asia (in fact, on the territory of present Uzbekistan). It had been forming for several centuries under special conditions[1]. In fact, there are many reasons for the Tatars being scattered on all the territory of Eurasia. In the second half of the 19th century, the situation changed: Tatars in Central Asia, apart from trade, began to exert cultural and, after the 1905 events, social impact on local people. Those were Tatars who initiated opening of Jadidist schools. The first Book Publishing Houses and, after 1905, print media started developing. Contradicting the emperor reign policy, that process made them change their policy in the region.

Obviously, the imperial government could not possibly watch the economic development of Tatars and the increase of their cultural influence on friendly peoples of Kazakhstan and Central Asia. While implementing the national colonial policy and taking into account the interests of Russian merchants, Russian tsarism created many different obstacles to cultural and economic development of Tatars in the region. According to the 262 article of the 1886 'Regulations on the administration of the Turkestan region', Tatars were not allowed to buy properties, i.e. land, houses and shops in that region. Those rules hurt the Tatars that moved to Turkestan [Litvinov].

In the early 20th century Tatars enriched the cultural, social and political life of Central Asia with the new forms of the new era. They established charitable societies, various cultural, educational, youth organizations and the first women's societies in the region (see Table 1). Those organizations played a crucial part in the formation of a new society in Central Asia, as the latest region to be included to Russia from the chronological standpoint. It should be mentioned that some societies were established in conjunction with the local people and promoted collaboration between the two nations. For instance, at the beginning of August, in 1917, the Tatar and Uzbek youth of the city of Samarkand organized theatre and music society and decided to donate 75% of their profits to the 'Khörriyat' (Freedom) newspaper and 25% to the Tatar bureau respectively [The Samarkand News].

The advanced part of the Central Asian Tatars welcomed the February Revolution that could be seen in the telegrams sent to the State Duma [Russian State Historical Archive].

At that time, one by one, new socio-political organizations were born in different regions of Turkestan. On April 4, 1917, at the general meeting of Tashkent Tatars the 'Ittifak' (Union) society was formed with the aim of promoting the ideas of

[1] For more information about the formation of the Tatar diaspora and the related scientific literature refer to [Gilyazov].

civic society among people and affiliating all Muslims in Turkestan [Səyfelmölek. The 'Ittifak' society]. The society sent six people to the Executive Committee, the District and City Food Committees, two to each organization. Having been appointed by the Tsar and having been served as Imam for 22 years, Conservative Imam M. Akhtyamov was fired at the society's initiative for 'violating the Islam Shariah and sabotaging people'.

The city of Andizhan became one of the most active centres of the Tatar social movement. In 1917 the three Tatar organizations – 'The first Muslim charitable society of Andizhan', the 'Uyanu' (Awakening) club and 'The Muslim women's society' were established there [Nurmukhammadi]. Being organized by the Tatar youth, the 'Uyanu' club was particularly active: they opened a library, staged performances in favour of the Tatar organizations of Andizhan, and formed a special committee for educating local people. Under the leadership of the gymnasium student Rabiga Safarova 'The Muslim women's society' launched the courses for elderly women. The leader of the society 'educated poor Muslim women at home for free'.

On April 13–20, 1917, Turkic-Tatar Kurultay (National Congress) of the Turkestan region was held to keep the socio-political movement [Səyfelmölek. The Congress of Turkestan Tatars]. There were 25 representatives from Andizhan, Kokand, Kattakurgan, Namangan, Akmechet, Kazaly, Termez, Bokhara and other cities there. The main outcomes of Kurultay were as follows:

1) To form the 'Central Bureau of Turkestan Turkic-Tatars' in Tashkent in order to unite all Tatar organizations of the Turkestan region and monitor their political, economic and social activities.

2) To prepare reports for the representatives to be sent to the first All-Russian Muslims Congress, taking place in Moscow on May 1.

3) To cooperate with the local people of the Turkestan region, and at the same time to establish special organizations in order to satisfy the needs of Turkestan Tatars.

4) To establish organizations administered by the Central Bureau of Turkestan Tatars in Tashkent with the aim of promoting political, economic and educational development of Tatars in every part of Turkestan.

5) The Central Bureau initiated the publication of the 'Olug Törkestan' (The Great Turkestan) newspaper and started collecting the donations for the newspaper. In fact, the Central Bureau of Turkestan Tatars released 155 issues of the 'Olug Törkestan' newspaper (from April 25, 1917, to November 26, 1918). The newspaper, under the editorship of Kabir Baker, made a prominent mark on the socio-political movement of Turkestan Tatars.

On July 13–15, 1917 the Council meeting, playing an important role in the socio-political movement of Turkestan Tatars, was held [Meetings of Turkestan Tatars]. At the meeting Khafiz Yangulatov was chosen as the representative for the Second All-Russian Muslim Congress in Kazan. He was instructed in the questions concerning the creation of favourable conditions for the participation of Turkestan women in the elections for the Constituent Assembly and the formation of a separate Muslim faction defending the rights and interests of Muslims in the Constituent Assembly. Their agenda also included some organizational issues. As some members of the Central Bureau were often absent from its meetings for a variety of reasons and some of them could not take time out of their work, the activity of the Bureau was found unsatisfactory. It was decided to elect new members and prepare new statutes. The following members were included into the Bureau: Abubaker Divaev (a chairman), Kabir Baker (a deputy chairman), Ibneyamin Yanbaev (a secretary), Rakhim Tyuminev (a treasurer) and Gabdullazhan Safagaraev (his deputy).

However, in 1918 the political situation took a bad turn for the Tatar organizations of Central Asia. On April 28, 1918, the Red Army soldiers arrested 15 members of the most active 'Ittafak' society during the session by the order of 'commissaries from Moscow'. The news came to the 'Muslim commissaries' who participated in the session of Bolsheviks in the 'Freedom House', and Garif Klevleev (?–1919), being a representative of the National Commissariat in Turkestan and Deputy Chairman of the Central Executive Committee of Turkestan, released them [The arrest of the members of 'Ittifak'].

As the dictatorship of Bolsheviks and the Soviet power strengthened their positions, the independent socio-political movement of the Tatars in Central Asia was coming to its end.

Table 1

**The Tatar Socio-Political Organizations in Central Asia**

| № | Name of organization | Location | Ethnic structure | Date of formation |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 'Chishmə' | | Tatars | 1910 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | music and drama club | | | |
| 2 | Krasnovodsk Muslim Committee on Construction of Mosques and Schools | the city of Krasnovodsk | Tatars | not later than March 27, 1914 |
| 3 | Muslim Society on Providing Help to Injured Military Personnel | the city of Bokhara | Tatars | not later than December 14, 1914 |
| 4 | Muslim Society on Providing Help to Injured Military Personnel | the city of Tashkent | Tatars | late August, 1914 |
| 5 | Theatre and Music Club | the city of Samarkand | Tatars | not later than June 17, 1914 |
| 6 | Muslim Charitable Society | the city of Temez | Tatars | 1915 |
| 7 | Muslim Charitable Society | the city of Kerki | Tatars | not later than May 3, 1915 |
| 8 | Temporary Tatar club | the city of Bokhara | Tatars | not later than January 12, 1915 |
| 9 | Urgench Muslim Charitable Society | the city of Urgench | Tatars | 1915 |
| 10 | Muslim Charitable Society | the city of Kungrad | Tatars | not later than June 17, 1916 |
| 11 | The ‘Chulpan’ Music and Drama Club | the city of Tashkent | Tatars | the early 1916 |
| 12 | The ‘Sənəigy nəfisə’ Society | the city of Kokand | Tatars | July 16, 1917 |
| 13 | Theatre and Music Society | the city of Samarkand | Tatars, Uzbeks | not later than August 3, 1917 |
| 14 | Muslim WOMEN’S PUBLISHING and Educational Society | the city of Tashkent | Tatars | early April, 1917 |
| 15 | Theatre Mahallya Society | the city of Auliye-Ata | Tatars | early August, 1917 |
| 16 | Tatar Publishing and Educational Society | the city of Tashkent | Tatars | not later than July 19, 1917 |
| 17 | ‘Zhəmgiyate islam’ | the city of Namangan | Tatars | not later than April 18, 1917 |
| 18 | The ‘Maksud’ Society | the city of Tashkent | Tatars, Uzbeks | June 7, 1917 |
| 19 | The Tatar ‘Ittifak’ Society | the city of Skobelev | Tatars | April 28, 1917 |
| 20 | Parents’ Committee | the city of Tashkent | Tatars | October 27, 1917 |
| 21 | Muslim Youth Club | the city of Perovsk | Tatars, Uzbeks | April 26, 1917 |
| 22 | ‘The Muslim Women’s Society’ | the city of Andizhan | Tatars | May 20, 1917 |
| 23 | Kazaly Tatar Charitable Society | the city of Kazaly | Tatars | not later than April 12, 1917 |
| 24 | The ‘Ittifak’ Society | the city of Tashkent | Tatars | April 4, 1917 |
| 25 | Muslim Charitable Society | the city of Chardzhou | Tatars | May 29, 1917 |
| 26 | The ‘Islam nury’ Society | the city of Kattakurgan | Tatars, Uzbeks | April 5, 1917 |
| 27 | The ‘Ittikhad və tərəkkyi’ Society | the city of Kattakurgan | Tatars | after February, 1917 |
| 28 | ‘Ittifaky islamiya’ | the city of Andizhan | Tatars | April, 1917 |
| 29 | The Society on the Advancement of Learning among Muslims | the city of Kokand | Tatars | not later than April 25, 1917 |
| 30 | The ‘Uiganu’ Youth Club | the city of Andizhan | Tatars | May 8, 1917 |
| 31 | The ‘Ittifak’ Society | the city of Fergana | Tatars | early April, 1917 |
| 32 | ‘The First Muslim Charitable Society of Andizhan | | Tatars | May 11, 1917 |
| 33 | The society of Muslim | the city of Andizhan | Tatars | not later than May |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Students of State General-Education Schools | | | 21, 1917 |
| 34 | Muslim Charitable Society | the city of Khujand | Tatars, Uzbeks | not later than May 2, 1917 |
| 35 | Muslim Teachers' Club | the city of Tashkent | Tatars | not later than July 27, 1917 |
| 36 | Islamic Society | the city of Chimkent | Tatars | December 29, 1917 |

The Table is based on the following sources: [Atlasov], [Baikot], [G. T. Hukand], [Izmetyev], [The 'Yoldyz' correspondent], [Societies], [Donation to charitable society], [Zukay], [Kuchkarova. Kattakurgan], [Kuchkarova. Chardzhou], [Kattakurgan], [The 'Maksud' society], [Subay], [Əlif], [Donations in Namangan], ['Nəüm'], [Nugaev], [Səyfelmölek. The 'Ittifak' society], [Perovsk], [The parents' committee], [The Samarkand news], [Skobelev], [Sultanbekovo], [Tazhetdinov], [Tashkent Muslim Women's Aid Committee], [The Tashkent news], [The Turkestan news], [Khasanzada], ['Shəekh' (Sheikh)], [The life of Tatar society in Chimkent], [Yausheva].

**References**

Abdullaev, R. (2008). *Musul'manskie obshchestvennye organizatsii Turkestana v 1917 godu* [Muslim Communities in Turkestan in 1917]. Islamskie tsennosti Tsentral'noi Azii: tolerantnost' i gumanizm. Istoriko-filosovskie i kul'turnye aspekty. Pp. 54–60. Tashkent. (In Russian)

Alif, M. (1917). *Andizhan*. Olug Torkestan. 20 mai. (In Tatar)

Atadzhanov, A. R. (1997). *"Shuro-i-islamiia" kakova ona byla v deistvitel'nosti?* ["Shuro-i-Islamiya" – What Was It Like In Reality?"]. Istoriya natsional'nykh politicheskikh partii Rossii. Materialy mezhdunarodnoi konferentsii. Pp. 201–205. Moscow: ROSSPEN. (In Russian)

Atlasov, M. (1917). *Andizhan*. Vakyt. 16 iyun. (In Tatar)

*Baikot.* (1917). Olug Torkestan. 27 iyun. (In Tatar)

*Chimkenttagy tatar zhamgyiatenen hayate* (1918) [Life of Tatar Community in Chimkent]. Olug Torkestan. 7 janvar. (In Tatar)

G. T. Khukand. (1917). *Tatarlarnyn hammatlary* [Tatar Achievements]. Olug Torkestan. 7 iyul. (In Tatar)

Gyilazhev, I. A. (2013). *Tatar diasporasy formalashunyn top uzenchaleklare* [Highlights of Tatar Diaspora Formation]. TATARICA. No. 1, pp. 158–170. (In Tatar)

Izmetyev, G. (1914). *Samarkandta teatr* [Theatre in Samarkand]. Vakyt. 17 iyun. (In Tatar)

*"Ittifak" agzalary* (1917) [Memebers of "Ittifak"]. Olug Torkestan. 30 aprel. (In Tatar)

*"Ioldyz" mokhbire. Tashkent tatarlary tormyshynnan* (1915) [From Tashkent Tatar's Life]. Ioldyz. 3 mai. (In Tatar)

Jausheva, M. (1917). *Khukand* [Khujand]. Olug Torkestan. 22 iyul. (In Tatar)

*Katta-Kurgan* (1917) [Kättä-Kurgan]. Olug Torkestan. 5 mai. (In Tatar)

Khafizov, G. G. (2003). *Kul'turtrigerskaya deiatel'nost' tatarskoi intelligentsii v XIX – pervoi chetverti XX vekov*. [Kulturträger Deeds of Tatar Intellectuals in the 19th and Early 20th Centuries]. Pp. 32–78. Kazan: Izd-vo Kazan. un-ta. (In Russian)

Khasanzada, G. (1914). *Krasnovodski moselmannary khalennan* [From Krasnovodsk Tatars' Life]. Vakyt. 27 mart. (In Tatar)

Kuchkarova, G. (1917). *Katta-Kurgan* [Kättä-Kurgan]. Olug Torkestan. 4 avgust. (In Tatar)

Kuchkarova G. (1917). *Charzhui*. Olug Torkestan. 14 iyun. (In Tatar)

Litvinov, P. P. (1995). *Antitatarskaia politika tsarizma v Srednei Azii i Kazakhstane* [Anti-Tatar Politics of Tsarism in the Central Asia and Kazakhstan]. Materialy po istorii tatarskogo naroda. 496 p. Kazan. (In Russian)

*"Maksud" zhamgyiate* (1917) ["Maksud" Community]. Olug Torkestan. 11 iyun. (In Tatar)

*Namanganda iganalar* (1917) [Donations in Namangan]. Tormysh. 2 mai. (In Tatar)

*"Naum". Tashkentta adabyat kichase* (1917) [A Literary Party in Tashkent]. Vakyt. 19 iyul. (In Tatar)

Nugaev, K. (1915). *Bokharada tatarcha teatr* [Tatar Theatre in Bukhara].Il. 30 gyinvar. (In Tatar)

Nurmokhammadi, G. (1917). *Firgana akhvale* [Life in Fergana]. Vakyt. 20 iyun. (In Tatar)

*Perovsk*. (1917). Olug Torkestan. 8 mai. (In Tatar)

*Roditel'skii komitet* (1917) [Parents' Committee]. Olug Torkestan. 8 noyabr. (In Russian)

*Rossiya Daulat tarikh arkhivy* [Archive of Russian State History]. 1278 f., 5 tasv., 1338 esh. P. 73. (In Tatar)

Saifelmolek, N. (1917). *"Ittifak" zhamgyiate* ["Ittifak" Community]. Olug Torkestan. 25 aprel. (In Tatar)

Saifelmolek, N. (1917). *Torkestandagy tatarlarnyn sjezdy* [The Congress of Turkestan Tatars]. Olug Torkestan. 25 aprel. (In Tatar)

*Samarkand khabarlare* (1917) [Samarkand News]. Khorriyat. 13 avgust. (In Tatar)

"Shaekh". (1914). *Bokhara* [Bukhara] . Vakyt. 14 dekabr. (In Tatar)

*Skobelev*. (1917). Olug Torkestan. 24 mai. (In Tatar)

Soltanbak. (1917). *Khatyn-kyz donyasynda* [In the Women's World]. Olug Torkestan. 1917. 25 aprel. (In Tatar)

Subai, M. (1917). *Kazaly.* Vakyt. 12 aprel. (In Tatar)

Tazhetdinov, B. (1917). *Auliya-Atada tatar makhallase zhamgyiate* [Tatar Community in Auliya-Ata]. Olug Torkestan. 4 noyabr. (In Tatar)

*Tashkent moslimalarenen yardam komitety* (1914) [Committee of Tashkent Muslim Women]. Vakyt. 4 sentyabr. (In Tatar)

*Tashkent khabarlare* (1917) [Taskent News]. Olug Torkestan. 20 mai. (In Tatar)

*Torkestan khabarlare* (1917) [Turkestan News]. Olug Torkestan. 24 mai. (In Tatar)

*Torkestan tatarlarynyn izhtimaglary* (1917) [Turkestan Tatars Meeting]. Olug Torkestan. 18, 22 iyul. (In Tatar)

*Zhamgyiatlar* (1917) [Communities]. *Koyash* [The Sun]. 21 mai. (In Tatar)

*Zhamgyiate khairiyaga igana* (1917) [Donations to the Good Deeds of Society]. Vakyt. 2 mai. (In Tatar)

*Zukai Kh. Kongyrat shaharennan* (1916). [From Kongurat]. Vakyt. 17 iyun. (In Tatar)

# XX ЙӨЗ БАШЫНДА УРТА АЗИЯ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ХӘРӘКӘТЕ

**Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
zminnullin@mail.ru.

Мәкаләдә Урта Азия татарларының XX йөз башындагы иҗтимагый-сәяси хәрәкәте яктыртыла. Тикшерү барышында, Урта Азиядәге (башлыча хәзерге Үзбәкстан Республикасы территориясендәге) Ташкент, Әндиҗан, Сәмәрканд, Фирганә һ. б. шәһәрләрдә 36 дан артык төрле иҗтимагый-сәяси оешмалар эшләве билгеле булды. Февраль инкыйлабыннан соң татарларның иҗтимагый-сәяси хәрәкәте яңа баскычка күтәрелә. Биредә татар вакытлы матбугаты барлыкка килә, бу төбәктәге татарларның үзәк органнары тарафыннан корылтайлар уздырыла. Совет хакимияте урнаша бару белән бергә, мөстәкыйль татар иҗтимагый-сәяси хәрәкәте тукталып кала.

**Төп төшенчәләр:** Урта Азия, яшьләр, хатын-кызлар, мәдәни-агарту, хәйрия оешмалары, диаспора, съезд.

Татар диаспорасы тарихы – Татарстан тарихы фәнендә узган гасырның 90 нчы елларында барлыкка килгән яңа юнәлешләрнең берсе. Аерым күзәтү рәвешендә язылган һәм монографик планда иҗат ителгән тикшеренүләр булуга карамастан, бу юнәлештә эшләнәсе эшләр күп, шактый тарихи проблемалар галимнәрнең игътибарыннан читтә кала бирә. Мәсәлән, Урта Азиядә XX йөз башы иҗтимагый-сәяси хәрәкәтенә багышланган соңгы еллардагы хезмәтләрдә татар оешмалары, гомумән, телгә алынмый [Абдуллаев], [Атаджанов], [Хафизов].

Сан ягыннан караганда, Урта Азиядә (асылда, хәзерге Үзбәкстан Республикасы территориясендә) татар диаспорасы иң зурлардан санала. Аның формалашуы бернichә гасырга сузылган һәм гаять үзенчәлекле шартларда барган[1]. Мәгълүм ки, татарның Евразия киңлекләренә сибелеп урнашуы күп төрле сәбәпләргә бәйләнгән. XIX йөзнең икенче яртысында вәзгыять үзгәрә: Урта Азиядә татарлар, сәүдә итүдән тыш, җирле халыкка мәдәни, 1905 еллардан соң сәяси яктан да тәэсир итә башлыйлар. Татарлар тарафыннан җәдиди мәктәпләр ачыла, басма китап, ә 1905 елдан соң татар вакытлы матбугаты тарала башлый. Патша хөкүмәте сәясәтенә туры килмәгән бу процесс, әлбәттә, хакимиятне төбәктәге сәясәтен үзгәртүгә этәрә.

Татарларның икътисадый яктан ныгуы һәм Казахстандагы, Урта Азиядәге кардәш халыкларга мәдәни йогынтысы көчәя баруын патша хөкүмәте тыныч кына күзәтеп тора алмый, әлбәттә. Милли-колониаль сәясәтне тормышка ашыра барып һәм рус эшкуарлары мәнфәгатьләрен күздә тотып, царизм бу төбәктә татарның икътисадый һәм мәдәни үсешенә төрле киртәләр куя. 1886 елда кабул ителгән «Төркестанны идарә итү турындагы кагыйдәләр» нең 262 нче маддәсе нигезендә татарларга бу төбәктә күчми торган милек, ягъни җир

[1] Татар диаспорасы формалашуның үзенчәлекләре һәм бу турыда фәнни әдәбият хакында тәфсилләбрәк кара: [Гыйләҗев].

участоклары, йортлар, кибетләр сатып алу тыела. Бу кагыйдәләр Төркестанга күчеп килгән татарларны авыр хәлгә куйган [Литвинов].

XX йөз башында татарлар Урта Азиядәге мәдәни, иҗтимагый һәм сәяси тормышны Яңа заманга хас булган яңа формалар белән баеталар. Алар хәйрия җәмгыятьләре генә түгел, төрле мәдәни-агарту, яшьләр оешмалары, һәм, бу төбәктә беренчеләрдән булып, хатын-кыз җәмгыятьләре дә оештыралар (кара: Таблица 1). Хронологик яктан Россиягә иң соңгылардан булып кушылган Урта Азия өчен бу оешмалар яңа җәмгыять нигезләрен төзүдә мөһим роль уйныйлар. Шуны да әйтергә кирәк: кайбер җәмгыятьләр җирле халык вәкилләре белән бергәләп оештырыла һәм ике халык арасында хезмәттәшлек урнаштыруга хезмәт итә. Мәсәлән, 1917 елның август башында Сәмәрканд шәһәрендә татар һәм үзбәк яшьләре театр һәм музыка җәмгыяте корып, төрле чаралардан кергән керемнең 75% «Хөррият» газетасына, 25% Татар бюросына бирергә карар кылалар [Сәмәрканд хәбәрләре].

Урта Азия татарларының алдынгы өлеше Февраль революциясен шатланып каршы ала, алар тарафыннан Дәүләт Думасына юлланган телеграммалар нәкъ шул хакта сөйли [Россия Дәүләт тарих архивы].

Бу чорда Төркестанның төрле төбәкләрендә бер-бер артлы яңа иҗтимагый-сәяси оешмалар барлыкка килә. 1917 елның 4 апрелендә Ташкент татарларының гомуми җыелышында, халык арасында гражданлык идеяләрен тарату һәм Төркестан мөселманнарын «бер ноктага җыю» максаты белән «Иттифак» җәмгыяте төзелә [Сәйфелмөлек. «Иттифак» җәмгыяте]. Бу җәмгыять тарафыннан шәһәрдәге Башкарма комитетка, Өлкә һәм шәһәр азык-төлек комитетларына икешәрдән, барысы алты кеше җибәрелә. Патша хөкүмәте тарафыннан куелып, 22 ел имамлык иткән һәм «Шәригатькә хилаф вә халыкка зарарлы күп эшләр эшләгән» кадимче имам М. Әхтәмов җәмгыять тарафыннан эшеннән алына.

Әндиҗан шәһәре татар иҗтимагый хәрәкәтенең иң актив үзәкләреннән берсе була. 1917 елда биредә өч татар оешмасы – «Беренче Әндиҗан мөселман җәмгыяте хәйриясе», «Уяну» түгәрәге, «Мөслимәләр җәмгыяте» барлыкка килә [Нурмөхәммәди]. Татар яшьләре тарафыннан оештырылган «Уяну» түгәрәге аеруча актив эш алып бара: китапханә ача, Әндиҗандагы татар оешмалары файдасына спектакльләр куя, җирле халык арасында төрле яклап агарту эшләре алып бару өчен, махсус комиссия төзи. Гимназистка Рәбига туташ Сәфәрова җитәкчелегендәге «Мөслимәләр җәмгыяте» өлкән яшьтәге хатын-кызлар өчен уку курслары ача. Җәмгыять җитәкчесе «ярлы мөслимәләрне өйләренә барып бушлай укыта».

Иҗтимагый-сәяси хәрәкәтне оешкан төстә алып бару өчен, 1917 елның 13–20 апрелендә Ташкентта Төркестан төбәгендәге төрки-татарларның корылтае уздырыла [Сәйфелмөлек. Төркестандагы татарларның съезды]. Анда Әндиҗан, Хуканд, Кәттә-Курган, Нәманган, Акмәчет, Казалы, Термиз, Бохара һәм башка шәһәрләрдән 25 вәкил катнаша. Корылтайда түбәндәге мөһим карарлар кабул ителә:

1) Бөтен Төркестан төбәгендәге татар оешмаларын берләштерү, алар белән сәяси, икътисадый һәм иҗтимагый эшләрдә җитәкчелек өчен, Ташкентта «Төркестандагы төрки-татарларның Мәркәз бюросы» төзелә.

2) Беренче майда Мәскәүдә булачак беренче Бөтенрусия мөселман корылтаена җибәреләчәк вәкилләргә докладлар әзерләү.

3) Төркестандагы җирле халыклар белән берлектә эш итү һәм шул ук вакытта Төркестандагы татарларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен үз оешмаларын булдыруны да кирәк табалар.

4) Төркестанның һәр төбәгендә, сәяси, икътисадый һәм гыйльми җәһәттән, татарларның үсешенә ярдәм итә торган оешмалар төзү һәм аларны Ташкентта булган Гомумтөркестан татарларының Мәркәз бюросына буйсындыру алга сөрелә.

5) Мәркәз бюро исеменнән Ташкентта «Олуг Төркестан» исемле газета чыгарырга карар бирелә һәм шунда ук газета фондына иганә җыю оештырыла. Мәгълүм ки, Төркестандагы татарларның мәркәз бюросы тарафыннан «Олуг Төркестан» газетасының (1917 елның 25 апреленнән 1918 елның 26 ноябренә кадәр) 155 саны нәшер ителә. Мөхәррире Кәбир Бәкер булган бу газета Төркестан татарларының иҗтимагый-сәяси хәрәкәтендә тирән эз калдыра.

1917 елның 13–15 июль көннәрендә Төркестан татарларының иҗтимагый-сәяси хәрәкәтендә зур роль уйнаган Киңәш җыелышы булып уза [Төркестан татарларының иҗтимаглары]. Анда Казанда булачак Икенче Бөтенрусия мөселман корылтаена вәкил итеп, Хафиз Янгулатов сайлана, аңа Учредительный Собраниегә сайлауларда Төркестан хатын-кызларының катнашуы өчен уңай шартлар тудыру, Учредительный Собраниедә мөселман-

нарның мәнфәгать һәм хокукларын яклаучы аерым мөселман фракциясе төзү мәсьәләләре буенча наказлар бирелә. Шулай ук бу Киңәш җыелышында оештыру мәсьәләләре дә карала. Мәркәз бюро әгъзаларының бер өлеше төрле сәбәпләр белән читкә китүе, ә кайберләренең үз эшләреннән аерылып эшли алмаулары сәбәпле, бюроның эшләре тиешле дәрәҗәдә бармый дип табыла һәм аңа яңа әгъзалар кабул итәргә, яңа устав төзергә карар бирелә. Яңа составка түбәндәге шәхесләр кертелә: Әбүбәкер Диваев (рәис), Кәбир Бәкер (рәис урынбасары), Ибнеямин Янбаев (сәркәтип), Рәхим Тюминев (хәзинәдар) һәм Габдуллаҗан Сафагәрәев (аның урынбасары).

Әмма 1918 елда сәяси вәзгыять Урта Азиядәге татар оешмаларына карата тискәре юнәлеш ала. 1918 елның 28 апрелендә, «Мәскәүдән килгән комиссарларның» боерыгы буенча, Ташкенттагы иң эшлекле «Иттифак» җәмгыяте идарәсенең 15 әгъзасы идарә утырышы вакытында, Кызыл Армия солдатлары тарафыннан кулга алына. Бу вакыйга тиз арада «Ирек йорты»нда большевиклар фракциясе утырышында катнашкан «мөселман комиссарларга» хәбәр ителә һәм Милләтләр эше буенча халык комиссариатының Төркестандагы вәкиле, Төркестан Үзәк башкарма комитеты рәисе урынбасары Гариф Клевлеев (?–1919) «автомобиль илә» барып, аларны азат итә [«Иттифак» әгъзаларын тәүкыйф].

Большевиклар диктатурасы һәм совет хакимияте ныгып урнашу дәверендә Урта Азиядәге мөстәкыйль татар иҗтимагый-сәяси хәрәкәте сүнүгә таба йөз тота.

Таблица 1

**Урта Азиядә татар иҗтимагый-сәяси оешмалары**

| № | **Оешманың исеме** | **Оешу урыны** | **Милли составы** | **Оешу вакыты** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | «Чишмә» музыка драма түгәрәге | | татарлар | 1910 ел |
| 2 | Мәчет һәм мәктәп төзү буенча Красноводск мөселман комитеты | Красноводск шәһәре | татарлар | 1914 елның 27 мартыннан да соң түгел |
| 3 | Яралы гаскәриләргә ярдәм итүче мөселман җәмгыяте | Бохара шәһәре | татарлар | 1914 елның 14 декабреннән дә соң түгел |
| 4 | Яралы гаскәриләргә ярдәм итүче мөселман җәмгыяте | Ташкент шәһәре | татарлар | 1914 елның август азагында |
| 5 | Театр һәм музыка түгәрәге | Сәмәрканд шәһәре | татарлар | 1914 елның 17 июненнән дә соң түгел |
| 6 | Мөселман хәйрия җәмгыяте | Термиз шәһәре | татарлар | 1915 ел |
| 7 | Мөселман хәйрия җәмгыяте | Керки шәһәре | татарлар | 1915 елның 3 маеннан да соң түгел |
| 8 | Вакытлы татар түгәрәге | Бохара шәһәре | татарлар | 1915 елның 12 гыйнварыннан да соң түгел |
| 9 | Яңа Үргәнч мөселман хәйрия җәмгыяте | Яңа Үргәнч шәһәре | татарлар | 1915 ел |
| 10 | Мөселман хәйрия җәмгыяте | Коңгырат шәһәре | татарлар | 1916 елның 17 июненнән дә соң түгел |
| 11 | «Чулпан» музыка-драма түгәрәге | Ташкент шәһәре | татарлар | 1916 ел башында |
| 12 | «Сәнәигы нәфисә» җәмгыяте | Коканд шәһәре | татарлар | 1917 ел , 16 июль |
| 13 | Театр һәм музыка җәмгыяте | Сәмәрканд шәһәре | татарлар, үзбәкләр | 1917 ел 3 августтан да соң түгел |
| 14 | Мөслимәләр нәшре мәгариф җәмгыяте | Ташкент шәһәре | татарлар | 1917 ел апрель башында |
| 15 | Театр мәхәлләсе җәмгыяте | Әүлия-Ата шәһәре | татарлар | 1917 елның август башында |
| 16 | Татар нәшре мәгариф җәмгыяте | Ташкент шәһәре | татарлар | 1917 елның 19 июленнән дә соң түгел |
| 17 | «Җәмгыяте ислам» | Наманган шәһәре | татарлар | 1917 елның 18 апреленнән дә соң түгел |
| 18 | «Максуд» җәмгыяте | Ташкент шәһәре | татарлар, үзбәкләр | 1917 ел, 7 июнь |
| 19 | «Иттифак» татар җәмгыяте | Скобелев шәһәре | татарлар | 1917 ел, 28 апрель |
| 20 | Ата-аналар | Ташкент | татарлар | 1917 ел, 27 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | комитеты | шәһәре | | октябрь |
| 21 | Мөселман яшьләр түгәрәге | Перовск шәһәре | татарлар, үзбәкләр | 1917 ел, 26 апрель |
| 22 | «Мөслимәләр җәмгыяте» | Әндиҗан шәһәре | татарлар | 1917 ел, 20 майдан да соң түгел |
| 23 | Казалы татар хәйрия җәмгыяте | Казалы шәһәре | татарлар | 1917 елның 12 апреленнән дә соң түгел |
| 24 | «Иттифак» җәмгыяте | Ташкент шәһәре | татарлар | 1917 ел, 4 апрель |
| 25 | Мөселман хәйрия җәмгыяте | Чаржау шәһәре | татарлар | 1917 ел, 29 май |
| 26 | «Ислам нуры» җәмгыяте | Кәттә-Курган шәһәре | татарлар, үзбәкләр | 1917 ел, 5 апрель |
| 27 | «Иттихад вә тәрәкъкый» җәмгыяте | Кәттә-Курган шәһәре | татарлар | 1917 ел, февральдән соң |
| 28 | «Иттифакы исламия» | Әндиҗан шәһәре | татарлар | 1917 ел, апрель |
| 29 | Мөселманнар арасында мәгърифәт тарату җәмгыяте | Хуканд шәһәре | татарлар | 1917 ел, 25 апреленнән дә соң түгел |
| 30 | «Уйгану» («Уяну») яшьләр түгәрәге | Әндиҗан шәһәре | татарлар | 1917 елның 8 маенда |
| 31 | «Иттифак» җәмгыяте | Фирганә шәһәре | татарлар | 1917 елның апрель башында |
| 32 | «Беренче Әндиҗан мөселман җәмгыяте хәйриясе» | | татарлар | 1917 ел, 11 май |
| 33 | Хөкүмәтнең урта мәктәп-ләрендә белем алучы мөселман шәкертләре җәмгыяте | Әндиҗан шәһәре | татарлар | 1917 елның 21 маеннан да соң түгел |
| 34 | Мөселман хәйрия җәмгыяте | Хөҗәнт шәһәре | татарлар, үзбәкләр | 1917 елның 2 маеннан соң түгел |
| 35 | Мөселман укытучылар түгәрәге | Ташкент шәһәре | татарлар | 1917 елның 27 июленнән дә соң түгел |
| 36 | Ислам җәмгыяте | Чимкент шәһәре | татарлар | 1917 елның 29 декабрендә |

Таблица түбәндәге чыганаклар нигезендә төзелде: [Атласов], [Байкот], [Г. Т. Хукандтагы татарларның һимматләре], [Изметьев], [«Йолдыз» мөхбире], [Җәмгыятьләр], [Җәмгыяте хәйриягә иганә], [Зукай], [Кучкарова. Кәттә-Курган], [Кучкарова. Чаржуй], [Кәттә-Курган], [«Максуд» җәмгыяте], [Субай], [Әлиф], [Нәмәнганда иганәләр], [«Нәүм»], [Нугаев], [Сәйфелмөлек. «Иттифак» җәмгыяте], [Перовск], [Родительский комитет], [Сәмәрканд хәбәрләре], [Скобелев], [Солтанбәк], [Таҗетдинов], [Ташкент мөслимәләренең ярдәм комитеты], [Ташкент хәбәрләре], [Төркестан хәбәрләре], [Хәсәнзадә], [«Шәех»], [Чимкенттагы татар җәмгыятенең һәйәте], [Яушева].

**Әдәбият**


*Атласов М.* Әндиҗан // Вакыт. 1917. 16 июнь.

*Әлиф М.* Әндиҗан // Олуг Төркестан. 1917. 20 май.

Байкот // Олуг Төркестан. 1917. 27 июнь.

Г. Т. Хукандтагы татарларның һимматләре // Олуг Төркестан. 1917. 7 июль.

*Гыйләҗев И. А.* Татар диаспорасы формалашуның төп үзенчәлекләре // TATARICA. 2013. № 1. Б. 158–170.

*Изметьев Г.* Сәмәркандта театр // Вакыт. 1914. 17 июнь.

«Иттифак» әгъзаларын тәүкыйф // Олуг Төркестан. 1917. 30 апрель.

«Йолдыз» мөхбире. Ташкент татарлары тормышыннан // Йолдыз. 1915. 3 май.

Җәмгыятьләр // Кояш. 1917. 21 май.

Җәмгыяте хәйриягә иганә // Вакыт. 1917. 2 май.

*Зукай Х.* Коңгырат шәһәреннән // Вакыт. 1916. 17 июнь.

Кәттә-Курган // Олуг Төркестан. 1917. 5 май.

*Кучкарова Г.* Кәттә-Курган // Олуг Төркестан. 1917. 4 август

*Кучкарова Г.* Чаржуй // Олуг Төркестан. 1917. 14 июнь

«Максуд» җәмгыяте // Олуг Төркестан. 1917. 11 июнь.

Нәмәнганда иганәләр // Тормыш. 1917. 2 май.

«Нәүм». Ташкентта әдәбият кичәсе // Вакыт. 1917. 19 июль.

*Нугаев К.* Бохарада татарча театр // Ил. 1915. 30 гыйнвар.

*Нурмөхәммәди Г.* Фирганә әхвале // Вакыт. 1917. 20 июнь.

Перовск // Олуг Төркестан. 1917. 8 май.

Родительский комитет // Олуг Төркестан. 1917. 8 ноябрь.

Россия Дәүләт тарих архивы. 1278 ф., 5 тасв., 1338 эш. Б. 73.

*Сәйфелмөлек Н.* «Иттифак» җәмгыяте // Олуг Төркестан. 1917. 25 апрель.

*Сәйфелмөлек Н.* Төркестандагы татарларның съезды // Олуг Төркестан. 1917. 25 апрель.

Сәмәрканд хәбәрләре // Хөррият. 1917. 13 август.

Скобелев // Олуг Төркестан. 1917. 24 май.

*Солтанбәк.* Хатын-кыз дөньясында // Олуг Төркестан. 1917. 25 апрель.

*Субай М.* Казалы // Вакыт. 1917. 12 апрель.

*Таҗетдинов Б.* Әүлия-Атада татар мәхәлләсе җәмгыяте // Олуг Төркестан. 1917. 4 ноябрь.

Ташкент мөслимәләренең ярдәм комитеты // Вакыт. 1914. 4 сентябрь.

Ташкент хәбәрләре // Олуг Төркестан. 1917. 20 май.

Төркестан хәбәрләре // Олуг Төркестан. 1917. 24 май.

Төркестан татарларының иҗтимаглары // Олуг Төркестан. 1917. 18, 22 июль.

*Хәсәнзадә Г.* Красноводски мөселманнары хәленнән // Вакыт. 1914. 27 март.

«Шәех». Бохара // Вакыт. 1914. 14 декабрь.

Чимкенттагы татар җәмгыятенең һәйәте // Олуг Төркестан. 1918. 7 январь.

*Яушева М.* Хуканд // Олуг Төркестан. 1917. 22 июль.

*Абдуллаев Р.* Мусульманские общественные организации Туркестана в 1917 году // Исламские ценности Центральной Азии: толерантность и гуманизм. Историко-философские и культурные аспекты. Ташкент, 2008. С. 54–60.

*Атаджанов А. Р.* «Шуро-и-исламия» – какова она была в действительности ? // История национальных политических партий России. Материалы международной конференции. М.: РОССПЭН, 1997. С. 201–205.

*Литвинов П. П.* Антитатарская политика царизма в Средней Азии и Казахстане // Материалы по истории татарского народа. Казань. 1995. 496 с.

*Хафизов Г. Г.* Культуртригерская деятельность татарской интеллигенции в XIX – первой четверти XX веков. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2003. С. 32–78.

---

# ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКОЕ ДВИЖЕНИЕ ТАТАР СРЕДНЕЙ АЗИИ В НАЧАЛЕ XX ВЕКА

**Завдат Салимович Миннуллин,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
zminnullin@mail.ru.

В статье охарактеризовано общественно-политическое движение татар Средней Азии в начале XX века. В ходе исследования выявлено, что в Средней Азии (территория современной Республики Узбекистан), в городах Ташкент, Андижан, Самарканд, Фергана и др., функционировало свыше 36 различных общественно-политических организаций. После Февральской революции татарское общественно-политическое движение поднимается на новую ступень. На этой территории активно развивается периодическая печать на татарском языке, по инициативе центральных органов татар созываются курултаи. Деятельность татарских общественно-политических организаций была ликвидирована с установлением Советской власти.

**Ключевые слова:** Средняя Азия, молодежь, женщины, культурное просвещение, благотворительные организации, диаспора, съезд.